# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылы торак пунктында
2025 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 20 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Әлмәт авылы территориясендә I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан тыш, Әлмәт авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Әлмәт авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту;

2) Әлмәт торак пунктының Ленин ур., Тукай ур., Яшьләр ур., Л. Рәхмәтуллин ур. буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материалларны сатып алу һәм транспортировкалау, эш өчен килешү буенча түләү) ;

3) Әлмәт торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

4) Әлмәт торак пунктында торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); МТЗ 82.1 тракторына, триммерлар һәм генератор өчен ягулык-майлау материаллары, МТЗ 82.1тракторына, триммерларга запас частьләр сатып алу);

3. Әлеге карарны Әлмәт авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Д.Ә.Газизов